МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.11.2022 Казан ш № 1030

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне (алга таба – Үзгәрешләр) расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 18.11.2022 ел, №1030 боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.07.2015 №461, 09.11.2015 №821, 07.06.2016 №317, 20.07.2016 №420, 28.11.2016 №668, 27.02.2017 №104, 08.06.2017 №349, 28.05.2018 №401, 18.09.2018 №857, 04.02.2019 №77, 07.05.2019 №322, 10.09.2019 №689, 14.11.2019 №1021, 24.03.2020 №192, 13.07.2020 №502, 02.10.2020 №691, 24.02.2021 №102, 21.05.2021 №331, 06.08.2021, №567, 01.10.2021 №710, 13.04.2022 №273 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламентында:

1 бүлекнең 1.2 пунктында:

11 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә социаль ярдәм чараларына хокуклы инвалидлар;

14 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) Чернобыль һәлакәте аркасында инвалидка әйләнгән затлар, түбәндәгеләр исәбеннән:

зарарланган зона чикләрендә һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан яисә эксплуатацияләү эшләренә җәлеп ителгән яки Чернобыль АЭСында башка эшләрдә катнашкан гражданнар (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яисә командировкаланган);

махсус җыеннарга чакыртылган, зарарланган зона чикләрендә Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерү белән бәйле эшләр башкаруга җәлеп ителгән хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби бурычлы кешеләр, урнашу урынына һәм башкарылган эшләренә бәйсез рәвештә, шулай ук читләштерү зонасында хезмәт иткән (итүче) эчке эшләр органнары, Янгынга каршы дәүләт хезмәте җитәкчеләре һәм гади хәрби хезмәткәрләр составындагы затлар;

зарарланган зоналардан эвакуацияләнгән һәм читләштерү зонасыннан күчерелгән яисә күрсәтелгән зоналардан эвакуацияләү турында карар кабул ителгәннән соң ирекле тәртиптә чыгып киткән гражданнар;»;

32 пунктта «мөрәҗәгать итү датасына» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 бүлектә:

2.2.2 пунктта «, КФҮ ерактагы эш урыннарында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.4.2 пунктның икенче абзацында «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар» сүзләрен «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлар» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.3.4  һәм 2.3.5 пунктларын өстәргә:

«2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.5. Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар реквизитлары:

торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар реквизитлары:

торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү нигезләре;

вәкаләтле затның вазыйфасы;

Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында мәгълүмат.»

2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар почта аша юллап җибәрелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында яки Бердәм порталда шәхси кабинет аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында яки Бердәм порталда шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документлар тикшерү» статусы бирелгән көннән башлап ун эш көне эчендә күрсәтелә.

2.6.1 пунктның 6 абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

2.6.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.9. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була);consultantplus://offline/ref=398B5C2B5B95C32AD6328A7E8A16E61AB94518EE5190DE2D9600CEA279E8ED300096477A0604BAD68FA1B699D8R0oCHconsultantplus://offline/ref=398B5C2B5B95C32AD6328A7E8A16E61ABE4118EA5192DE2D9600CEA279E8ED300096477A0604BAD68FA1B699D8R0oCHconsultantplus://offline/ref=398B5C2B5B95C32AD6328A7E8A16E61AB94518ED5893DE2D9600CEA279E8ED300096477A0604BAD68FA1B699D8R0oCH

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында - Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);consultantplus://offline/ref=398B5C2B5B95C32AD6328A7E8A16E61AB94518EE5190DE2D9600CEA279E8ED300096477A0604BAD68FA1B699D8R0oCHconsultantplus://offline/ref=398B5C2B5B95C32AD6328A7E8A16E61ABE4118EA5192DE2D9600CEA279E8ED300096477A0604BAD68FA1B699D8R0oCHconsultantplus://offline/ref=

398B5C2B5B95C32AD6328A7E8A16E61AB94518ED5893DE2D9600CEA279E8ED300096477A0604BAD68FA1B699D8R0oCH

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алу турында - Россия Федерациясе Пенсия фондыннан; (әлеге абзац таләбе 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була);

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләүне алу турында - Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында - Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торак бинага милек хокукы турында - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән;

төрләренең исемлеге 126 номерлы Нигезләмә кушымтасында күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында (хезмәт ветераннарына компенсация билгеләү өчен) – Федераль салым хезмәтеннән;

бала тууын дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен) – Федераль салым хезмәтеннән;

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, баланы тәрбиягә гаиләгә тапшыру турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен) – җирле үзидарә органнарыннан;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен) – Федераль салым хезмәтеннән;

аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен) – Федераль салым хезмәтеннән;

инвалидлык билгеләү факты турында (инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә компенсация билгеләү өчен) – Федераль медик-социаль экспертиза бюросыннан;

әгәр мөрәҗәгать итүче 14 яшенә җитмәгән балигъ булмаган зат булса, законлы вәкил вәкаләтләрен раслау өчен балага опека (попечительлек) билгеләнүе турында – җирле үзидарә органнарыннан;

хосусый шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан (әлеге абзац таләбе 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була);

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

салымнар һәм җыемнар буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бурыч булуы (булмавы) турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен) (әлеге абзац таләбе 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында (әлеге

Регламентның 1.2 пунктының 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләнгән очракта) – Федераль салым хезмәтеннән (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

мөрәҗәгать итүчедә торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткүгә түләү буенча законлы көченә кергән суд акты белән расланган, соңгы өч елдан артмаган чорда барлыкка килгән, түләнмәгән бурычның булуы (булмавы) турында – Торак-коммуналь хуҗалык дәүләт мәгълүмат системасыннан;

Россия Федерациясенең башка субъектында социаль ярдәм чараларын алу/алмау турында – Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан;

реабилитация турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

паспортның гамәлдә булуы турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

мөрәҗәгать итүченең федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка нигезләр буенча социаль ярдәм чараларын алуы турында (мөрәҗәгать итүчеләргә әлеге Регламентның 1.2 пунктының 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән компенсацияне билгеләү өчен) – Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан.

Мөрәҗәгать итүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләрне раслаучы документларны үз инициативасы буенча бирергә хокуклы.»;

2.8.1 пунктта «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар» сүзләрен «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлар» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

2.8.2 пунктының тугызынчы абзацында «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар» сүзләрен «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлар» сүзләренә алмаштырырга;

2.13.14 пунктта «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең ерактагы эш урыннарында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.14.1 пунктта «, КФҮ ерактагы эш урыннарында» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 бүлектә:

3.3.1 пунктның унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү

3.4.1. Үзәк бүлекчәсендә теркәлгән гариза рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

3.4.2. Үзәк бүлекчәсенең ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы булган белгече әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында каралган белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып).

3.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, сорала торган белешмәләрнең исемлеге:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була);

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында - Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алу турында - Россия Федерациясе Пенсия фондыннан; (әлеге абзац таләбе 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була);

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләүне алу турында - Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында - Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торак бинага милек хокукы турында - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән;

төрләренең исемлеге 126 номерлы Нигезләмә кушымтасында күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында (хезмәт ветераннарына компенсация билгеләү өчен) – Федераль салым хезмәтеннән;

бала тууын дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен) – Федераль салым хезмәтеннән;

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, баланы тәрбиягә гаиләгә тапшыру турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен) – җирле үзидарә органнарыннан;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен) – Федераль салым хезмәтеннән;

аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен) – Федераль салым хезмәтеннән;

инвалидлык билгеләү факты турында (инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә компенсация билгеләү өчен) – Федераль медик-социаль экспертиза бюросыннан;

әгәр мөрәҗәгать итүче 14 яшенә җитмәгән балигъ булмаган зат булса, законлы вәкил вәкаләтләрен раслау өчен балага опека (попечительлек) билгеләнүе турында – җирле үзидарә органнарыннан;

хосусый шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан (әлеге абзац таләбе 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була);

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

салымнар һәм җыемнар буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бурыч булуы (булмавы) турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләү өчен) (әлеге абзац таләбе 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә компенсация билгеләнгән очракта) – Федераль салым хезмәтеннән (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

мөрәҗәгать итүчедә торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткүгә түләү буенча законлы көченә кергән суд акты белән расланган, соңгы өч елдан артмаган чорда барлыкка килгән, түләнмәгән бурычның булуы (булмавы) турында – Торак-коммуналь хуҗалык дәүләт мәгълүмат системасыннан;

Россия Федерациясенең башка субъектында социаль ярдәм чараларын алу/алмау турында – Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан;

реабилитация турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

паспортның гамәлдә булуы турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

мөрәҗәгать итүченең федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка нигезләр буенча социаль ярдәм чараларын алуы турында (мөрәҗәгать итүчеләргә әлеге Регламентның 1.2 пунктының 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән компенсацияне билгеләү өчен) – Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан.

3.4.4. Әлеге Регламентның 2.6.9 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау

һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

3.4.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.9пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.»;

3.5.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Үзәк бүлекчәсе белгече әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек итү органнарыннан алынган белешмәләр һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:»;

3.5.4.1 пунктта:

беренче абзацта «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар» сүзләрен «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлар» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

бишенче абзацта «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар» сүзләрен «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлар» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

3.5.4.2 пунктның беренче абзацында «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар» сүзләрен «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлар» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе

2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

3.9 пунктта «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең ерактагы эш урыннарында» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 4.7 пункт өстәргә:

«4.7. Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

форма

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсенә

______________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА

Дата: «____» ____________ 20___ ел.

Мин,

______________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

яши торган адрес: ____________________________________________

______________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон почта адресы)

| Шәхесне раслаучы документ исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

Эш итү нигезе: ______________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эшләү вәкаләтен раслаучы документ реквизитлары)

Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация бирүегез турында сорыйм (кирәклесе астына сызарга)

_____________________________________________________

дәүләт хезмәтен алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счет номеры _____________

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

Билгеләнгән түләүләрне түбәндәгечә түләүне сорыйм:

счетка күчерү юлы белән

________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

почта бүлекчәсе аша җибәрергә

________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең яки законлы вәкилнең почта реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, аларны үз эченә алган документларның дөреслеге өчен җаваплылык турында һәм торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүдә субсидия түләүгә йогынты ясаучы шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турында нигезләмәләр белән таныштым

Мөрәҗәгать итүче: ________________________ _________ «___» ________ 20__ ел.

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (имза)

Гаиләм белән түбәндәге адрес буенча бергә яшәү фактын раслыйм:

________________________________________________________________

(гаиләнең яшәү адресы күрсәтелә, тәрбиягә алганнарын да кертеп, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзасы мөрәҗәгать иткәндә тутырыла)

Мөрәҗәгать итүче: ___________________________ _________ «___»

________ 20__ ел.

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (имза)

Мәгълүмат алу, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында мәгълүмат алуга риза: ______________________________

(почта адресы, смс-хәбәр, электрон почта адресы буенча, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинет аша яки Бердәм портал аша)

«___» ________ 20__ ел. Имза ______________________

Яңа вакытка социаль ярдәм чараларын автомат рәвештә билгеләү белән килешәм.

Мөрәҗәгать итүченең имзасы ________________________________________

(хезмәттән файдаланучы булып хезмәт ветераны торган очракта тутырыла)

Гариза һәм документлар кабул ителде _____________ 20_______ ел.

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү номеры

Документлар саны ____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте __________________ ___________ 20___ ел.

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нчы кушымта

«______________________________________»
карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

Кемгә_____________________________
(фамилия, исем, ата исеме)

Элемтә өчен мәгълүмат __________________
(Почта индексы һәм адрес)

торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында

КАРАР

№______________ Дата __________________

____________ башлап, гр. ______________ тарафыннан тапшырылган гариза һәм документлар ____________ каралды.

Бирергә _______________________________________________
(түләүнең аталышы)
гр. ___________________________________________________, _______ башлап ________ кадәр.
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (чор)
категория буенча: ______________

_________________________________ _________________________________
(Вәкаләтле хезмәткәрнең ФИА, вазыйфасы) (Электрон имза сертификаты турында белешмәләр)

Торак урынга түләү, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кертемен, коммуналь һәм башка төр хезмәтләр күрсәтүгә түләү чыгымнарына гражданнарның аерым категорияләренә компенсация билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар

_____________________________ билгеләүдән (бирүдән) баш тартырга
(түләүнең аталышы)
гр. ________________________________________________________,
мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

_________________________________ _________________________________
(Вәкаләтле хезмәткәрнең ФИА, вазыйфасы) (Электрон имза сертификаты турында белешмәләр)

түбәндәге сәбәпләр буенча: ______________________________

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча уңай нәтиҗә алу өчен гамәл кылу тәртибе турында аңлатмалар (конкрет киңәшләр күрсәтелә).
Әлеге карарга _________ яки суд тәртибендә шикаять белдерелә ала.

_____________________________ _________________________
(Вәкаләтле хезмәткәрнең ФИА, вазыйфасы) (Электрон имза сертификаты турында белешмәләр);

6 нчы кушымтада «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар» сүзләрен «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлар» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

кушымта (белешмәлек) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертем түләүдәге чыгымнарга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 17 сентябрендәге 856 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.01.2019 №8, 07.05.2019 №323, 14.11.2019 №1021, 21.04.2020 №257, 13.07.2020 №502, 02.10.2020 №102, 09.06.2021 №410, 23.11.2021 №863, 13.04.2022 №272 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертем түләүдәге чыгымнарга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2 бүлектә:

2.2.2 пунктта «, КФҮ ерактагы эш урыннарында» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.3.4 һәм 2.3.5 пунктлары белән тулыландырырга:

«2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.5. Компенсация билгеләү турында карар реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

Компенсация бирүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

компенсация бирүдән баш тарту турында карар кабул итү нигезләре;

вәкаләтле затның вазыйфасы;

Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.»;

2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар почта аша юллап җибәрелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге

Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинет аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документлар тикшерү» статусы бирелгән көннән башлап 10 эш көне эчендә күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычы булган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү бурычны түләгәнчегә кадәр, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәннән соң 90 көннән дә артык булмаган чорга туктатыла.»;

2.6 һәм 2.7 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

социаль түләүләр алу өчен федераль законнар нигезендә банкта яки башка кредит учреждениесендә ачылган счет реквизитларын күрсәтеп, компенсация бирү турында гариза:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге пункт таләпләре нигезендә имзалап, электрон формада (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, гаризаны нинди дә булса башка төрле формада өстәмә тапшыру зарурлыгыннан башка гына) интерактив форманы тутыру юлы белән);

аңа карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән торак урынга хокук билгеләүче документларның күчермәләре.

2.6.2. Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмалардан – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә дә алына.

2.6.3. Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре тарафыннан таныклана.

2.6.4. Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать иткәндә, үзләренең шәхесен таныклый торган һәм мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документтагы белешмәләр Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада

идентификация һәм аутентификация бердәм системасындагы (алга таба – БИАС) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

Физик зат тарафыннан бирелгән, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать итү хокукын раслаучы ышанычнамә нотариусның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән раслана.

2.6.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan№.ru) урнаштырылган.

2.6.6. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

Үзәк бүлекчәсенә яисә почта аша кәгазьдә;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинет аша гариза формасын тутыру юлы белән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша.

2.6.7. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

2.6.8. Гаризаны һәм кирәкле документларны «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасындагы документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

2.6.9. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар:

даими яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән берлектә теркәлгән гражданнар турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торак урынга милек хокукы турында – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән;

хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру факты турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан (әлеге абзац таләбе 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була);

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

хосусый шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия

фондыннан (әлеге абзац таләбе 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була);

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

Федераль медик-социаль экспертиза бюросыннан инвалидлык билгеләү фактын раслау турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булуы (булмавы) турында – Федераль салым хезмәтеннән (әлеге абзац таләбе 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында – Федераль салым хезмәтеннән (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

2.6.10. Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

2.6.11. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алынырга мөмкин.

2.6.12. Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булуы;

мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча карамаган Үзәк бүлекчәсенә мөрәҗәгать итүе;

Үзәк бүлекчәсенә 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру;

документларның күчермәләре тапшырылган очракта, күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, төп документларның күрсәтелмәве;

тапшырылган документларның хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган, дәүләт хезмәте

күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.»;

2.8.1 пунктта «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар» сүзләрен «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлар» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

түбәндәге эчтәлекле 2.8.3 пунктын өстәргә:

«2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.»;

2.13.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең инвалидларга башка затлар белән беррәттән, инвалидлар өчен хезмәтләр алуга комачаулаучы биналарның үтемлелеген тәэмин итү белән бәйле булмаган башка киртәләрне җиңүдә булышуы;»;

2.13.5 пунктта «, КФҮ ерактагы эш урыннарында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

2.14.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Үзәк бүлекчәсе, Үзәк, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында ИАБС системасында исәпкә алыну язуын раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә җибәрелә. БИАС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать итүченең, гаризаны имзалау өчен вәкаләтле мөрәҗәгать итүче вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

Гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта, әлеге Регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетка Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.

2.14.3. Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Үзәк бүлекчәсе телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Үзәк бүлекчәсе телефоны буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.14.4. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.»;

3 бүлектә:

3.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә дә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара гаризалар төзү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә гражданин шәхсән мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен тапшыру яки дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинеты аша җибәрү.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, Мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат алу;

гариза формалаштыру;

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәүгә алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу;

гариза карау барышы турында мәгълүмат алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Үзәк бүлекчәсе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) яисә Үзәк бүлекчәсенең вазыйфаи затлары яки дәүләт хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү.

Гаризаны карау барышы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу, авторизацияләнү шарты белән, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетта гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта үз инициативасы буенча шәхси кабинетта электрон гаризаның статусын, шулай ук алга таба башкарылачак гамәлләр турында мәгълүмат карау мөмкинлегенә ия.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр җибәрелә:

а) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итү һәм теркәү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү  һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының башлану факты турындагы белешмәләрне, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүне тәмамлау датасы һәм вакыты турындагы белешмәләрне яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән нигезле баш тартуны үз эченә алган белдерү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре турында белдерү, анда дәүләт хезмәте күрсәтү турында уңай карар кабул ителүе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе алу мөмкинлеге турында белешмәләр яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезле баш тарту була.»;

3.2.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, почта, электрон почта аша, техник мөмкинлек булганда, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша һәм (яки) Үзәк бүлекчәсенә дәүләт хезмәте күрсәтү

тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.»;

3.3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Мөрәҗәгать итүче компенсация билгеләү турында гаризаны Үзәк бүлегенә, әлеге Регламентның 2.6 пунктына туры китереп, документларны теркәп тапшыра.

63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (танықланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә электрон саклагыч җайланмаларыннан һәм «Интернет» челтәреннән файдаланып тапшырылырга мөмкин.

Үзәк бүлегенә почта аша, шул исәптән электрон почта буенча, җибәрелгән гариза гомуми тәртиптә карала.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында авторизация уза;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм риза булу фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Гаризаны формалаштырганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) гаризаның һәм әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларның күчермәләрен ясау һәм аларну саклау мөмкинлеге;

б) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

в) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

г) БИАС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, БИАС системасында урнаштырылган һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон гариза формасы кырларын тутыру;

д) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

е) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында бер елдан азрак булмаган чорда үзе элегрәк тапшырган гаризаларны, шулай ук кимендә өчай эчендә өлешчә формалаштырган гаризаларны карау мөмкинлеге.

Формалаштырылган һәм имзаланган гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар Үзәк бүлекчәсенә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.2 пункт өстәргә:

«3.3.2. Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Үзәк бүлечәсе белгече өчен электрон гаризаны алу мөмкинлеге «Татарстан Республикасы Халыкның социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында тәэмин ителә.

Үзәк бүлекчәсе белгече:

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан электрон гаризалар булу-булмавын көненә ике тапкырдан ким булмаган ешлыкта тикшерә;

алынган гаризаларны һәм теркәлгән документлар рәвешләрен карый.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында (3 нче кушымта) терки;

гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, беркетелгән керү номеры турында тамгалап (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), гаризаны мөрәҗәгать итүчегә язу тапшыру, почта аша, шул исәптән электрон почта аша, хәбәрләмә җибәрү (документлар почта, шул исәптән электрон почта, аша җибәрелгән очракта).

Документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту нигезләре булган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кайтарып бирә һәм мөрәҗәгать итүчегә, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тартуда ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша биргән очракта, гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яки гариза кергәндә – гариза һәм документлар килгән көнне;

гариза һәм документлар Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша килгәндә яки почта, электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә килгәндә, – гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенең эш вакыты тәмамлангач яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, киләсе эш көнендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәлгән язу, документларны кабул итүдән баш тарту турында язу яисә мөрәҗәгать итүчегә баш тарту турында хәбәр итү, мөрәҗәгать итүчегә кайтарылган документлар.»;

3.4.1 һәм 3.4.2 пунктларны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлекчәсендә теркәлгән гариза рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

3.4.2. Үзәк бүлекчәсенең ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы булган белгече әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, сорала торган белешмәләрнең исемлеге:

даими яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән берлектә теркәлгән гражданнар турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торак урынга милек хокукы турында – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән;

хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру факты турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан (әлеге абзац таләбе 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була);

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

хосусый шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия фондыннан (әлеге абзац таләбе 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була);

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

Федераль медик-социаль экспертиза бюросыннан инвалидлык билгеләү фактын раслау турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булуы (булмавы) турында – Федераль салым хезмәтеннән (әлеге абзац таләбе 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында – Федераль салым хезмәтеннән (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында рәсми мөрәҗәгать ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла

торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.»;

Әлеге Регламентның 2.6.9 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш итеlә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.9пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.»;

3.5.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Үзәк бүлекчәсе белгече әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек итү органнарыннан алынган белешмәләр һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:»;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Үзәк бүлекчәсе белгече дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә гаризада мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән (язмача формада

шәхсән яисә почта адресы буенча, электрон почта адресы буенча көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталына шәхси кабинетка, телефонга смс-хәбәр җибәрү юлы белән) бирә (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә шәхсән тапшырган очракта, компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында карар мөрәҗәгать итүчегә ул мөрәҗәгать иткән көндә тапшырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).»;

3.9 пунктта «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең ерактагы эш урыннарында» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 4.7 пункт өстәргә:

«4.7. Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.»;

6 нчы кушымтада «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар» сүзләрен «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлар» сүзләренә алмаштырырга.

кушымта (белешмәлек) үз көчен югалткан дип танырга.